Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге составына кергән Иске Чишмә торак пункты

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 21 октябреннән № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге Иске Чишмә торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге Иске Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кеше, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку бүлеге формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хатыны/ирләре азатителә, 500 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү белән килешәсезме, бу сумманың 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидлары, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр түли.

2. Алынган акчаларны канализацияне ремонтлауга (сатып алу, күчереп йөртү, җиһазлар урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), зиратны төзекләндерүгә (койма алу, ташу, урнаштыру, эшләр өчен түләү), Ленин урамы, Түбән Кама урамы юлларына чокырлы ремонт ясауга (сатып алу, ташу, асфальт салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) җибәрергә.

Җыелган гражданнарның үзара салым акчалары

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл җирлегенең Иске Чишмә торак пунктында 2018 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы чишмәләрне төзекләндерү өчен 1761,60 сум күләмендә гражданнар җыены карары буенча;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл җирлегенең Иске Чишмә торак пунктында 2019 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы карары белән Бакча, Пионер, Комсомол урамнары буйлап Иске Чишмә авылы юлларын төзүгә 47622,80 сум күләмендә гражданнар җыены карары буенча;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл җирлегенең Иске Чишмә торак пунктында гражданнар җыены карары буенча, 2020 елның 10 ноябрендәге 2 номерлы карары белән вак таш өслекле юлларны чокырлы төзекләндерүгә (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу,

шартнамә буенча эшләр өчен түләү) Иске Чишмә авылы Комсомол, Бакча, Маркин урамнары буенча 23305,20 сум күләмендә

Иске Чишмә авылындагы юлларны ямау (юлларны сатып алу, ташу, асфальт салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Чишмә авыл җирлеге башлыгы Ф.Х. Әхмәтов

«Совет Старошешминского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»